**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

19.10.2023 № 1347

«2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү программасын раслау турында» Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 29 маендагы 524 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында.

Россия Федерациясе Бюджет кодексына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Авыл хуҗалыгын үстерү турында» 2006 елның 29 декабрендәге 264-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 29 маендагы 524 номерлы карары белән расланган 2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Финанслау чыганакларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Финанслау чыганаклары | Программаны финанслауның гомуми күләме Нурлат муниципаль районы бюджеты акчалары хисабына 3 млн. 374 мең сум тәшкил итә, шул исәптән: 2023 ел -1 млн. 374 мең сум;<br>2024 ел-1,0 млн.сум;<br>2025 ел-1,0 млн.сум. |

1.2. 5нче бүлекнең 3нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Комиссия утырышлары елына ике тапкыр үткәрелә.».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

И.о. руководителя Ә.К. Габдуллин